***Якын дустым светофор***

Максаты: Юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам иттерү. Балаларда игътибарлылык тәрбияләү. Җәяүлегә урамда үзен ничек тотарга тиешлеген аңлату.

Җиһаз: Уенчык светофор, урам макеты, кызыл, яшел, сары түгәрәкләр. Светофор силуэты, пумала, җилем.

Дәрескә әзерлек: Машина юлына экскурсия, әңгәмәләр, дидактик уеннар оештыру.

Дәрес барышы:

- Балалар, бүген без сезнең белән юл кагыйдәләре турында сөйләшәбез.
  Песи керә: Мин мәче, юл кагыйдәләре белгече.
  Укытучы: Шундый белгеч булгач, әйдә, безнең балаларга да өйрәт. Я, әйтеп кара, машина юлыннан ничек чыгасы.
  Песи: Нәрсәсе бар аның, көпчәкләр арасыннан йөгерәсең дә чыгасың.
  Балалар: Көпчәкләр арасыннан йөгерсәң, көпчәк астында калуың бар! Юлны чыгар өчен , якында гына машиналар юкмы икәнен карарга кирәк.
  Укытучы: Мәче әйт әле, машина юлында уйнарга ярыймы?
  Песи: Ярый, кайда уйнасаң да ярый. Шулай бит, балалар.
  Балалар: Юк, мәче, син ялгышасың. Машина юлында уйнарга ярамый.
  Песи: Алайса кайда уйныйсы соң?
  Балалар: Ишек алдында.
  Укытучы: Мәче син, светофорның нәрсә икәнен беләсеңме?
  Песи: Беләм, ул өч күзле бер нәрсә инде шунда! Әле бер күзен ача, әле икенче күзен, әле өченче күзен ача.
  Балалар:
  Светофор ул җәяүлеләрнең дә, шоферларның да ярдәмчесе һәм дусты.
  Кызыл ут – тукта дигән сүз.
  Сары ут – игътибарлы бул.
  Яшел ут – барырга ярый.
  Песи: Балалар, сез бик күп нәрсәләр беләсез икән, хәзер мин сез сөйләгәннәрне истә тотармын.

Укытучы: Балалар, менә хәзер мәче белгечне тикшерәбез инде. Бергәләп уйнап алыйк әле.
Уен -“ Светофор”
Укытучы: Булдырдыгыз, барыгыз да светофор турында мәгълүматларны төгәл үзләштергәнсез.
Песи: Мин сезгә төрле төстәге түгәрәкләр алып килдем. Я, светофор ясап карагыз әле. Кемнеке матуррак булыр икән.
Балалар өстәл янына барып, әзер светофор силуэтына түгәрәкләрябыштыралар. Төсләрне дөрес урнаштыруларына ирешү. Эш беткәч, әзер эшләргә, песи йомгак ясый.